**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 25 апрель № 246

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2010 – 2015 елларга «Мәдәни мирас – Свияжск утрау-шәһәре һәм борынгы Болгар» комплекслы проектын раслау турында» 2010 ел, 9 декабрь, 1018 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2010 – 2015 елларга «Мәдәни мирас – Свияжск утрау-шәһәре һәм борынгы Болгар» комплекслы проектын раслау турында» 2010 ел, 9 декабрь, 1018 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 11 март, 181 нче; 2011 ел, 1 апрель, 247 нче; 2011 ел, 19 сентябрь, 776 нчы; 2011 ел, 31 октябрь, 903 нче; 2012 ел, 5 июнь, 483 нче; 2012 ел, 19 декабрь, 1104 нче; 2014 ел, 30 апрель, 286 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2010 – 2016 елларга «Мәдәни мирас – Свияжск утрау-шәһәре һәм борынгы Болгар» комплекслы проектын раслау турында»;

1 нче пунктта «2010 – 2015 еллар» сүзләрен «2010 – 2016 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган «2010 – 2015 елларга «Мәдәни мирас – Свияжск утрау-шәһәре һәм борынгы Болгар» комплекслы проектын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\246.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 9 декабрь, 1018 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 25 апрель, 246 нчы карары редакциясендә)

**2010 – 2016 елларга «Мәдәни мирас –**
**Свияжск утрау-шәһәре һәм борынгы Болгар»**
**комплекслы проекты**

2010 – 2016 елларга «Мәдәни мирас – Свияжск утрау-шәһәре
һәм борынгы Болгар» комплекслы проекты
паспорты

| | |
|---|---|
| Комплекслы проект исеме | 2010 – 2016 елларга «Мәдәни мирас – Свияжск утрау-шәһәре һәм борынгы Болгар» |
| Комплекслы проектны эшләү өчен нигез | «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 ел, 25 июнь, ФЗ-73 нче Федераль закон;<br>«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 ел, 1 апрель, ТРЗ-60 нчы Татарстан Республикасы Законы;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары;<br>ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитеты 38 нче сессиясенең Болгар тарих-археология комплексын Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертү турындагы 38 COM 8B.43 нче карары;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисенең 2009 ел, 30 декабрь, ВП-П44-7911 нче йөкләмәсе;<br>Россия Федерациясе Президентының 2015 ел, 24 март, Пр-508 нче йөкләмәсе;<br>Россия Федерациясе Дәүләт Советының һәм Россия Федерациясе Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать буенча советның 2014 елның 24 декабрендәге |

| | |
|---|---|
| | берләштерелгән утырышы йомгаклары буенча Россия Федерациясе Президенты йөкләмәләре исемлеге (2015 ел, 22 гыйнвар, Пр-93 нче), 3 нче пунктның «д» пунктчасы |
| Комплекслы проектның дәүләт заказчысы – яраштыручысы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| Комплекслы проектның техник заказчысы | «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе |
| Комплекслы проектны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;<br>«Татарстан мәдәни мирасы үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе;<br>«Татинвестгражданпроект» дәүләт унитар предприятиесе;<br>«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе |
| Комплекслы проектны үтәүчеләр һәм бергә үтәүчеләр | Проект, реставрацияләү һәм төзелеш оешмалары, мәдәният һәм фән учреждениеләре |
| Комплекслы проектның максаты | Россиянең уникаль истәлекле урыннары – Свияжск утраушәһәренең һәм борынгы Болгарның сакланышын һәм алардан нәтиҗәле файдалануны, аларны рухи, социаль-икътисадый һәм мәдәни торгызуны тәэмин итү |
| Комплекслы проектны тормышка ашыру вакытлары | 2010 – 2016 еллар |
| Ярдәмче проектлар исемлеге | «Тарихи һәм мәдәни мирасны өйрәнү һәм популярлаштыру»;<br>«Тарихи һәм мәдәни мирасның сакланышын тәэмин итү: ремонт-реставрация эшләре, шул исәптән хәзерге көндә файдалану өчен мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне) консервацияләү, ремонтлау, реставрацияләү һәм җайлаштыру, шулай ук мәдәни мирас объектларында фәнни-тикшеренү, тикшеренү, проект һәм җитештерү эшләре, фәнни-методик җитәкчелек, техник күзәтчелек һәм автор күзәтчелеге» |

| | |
|---|---|
| Комплекслы проектны финанслау күләме һәм чыганаклары | Комплекслы проект чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 5 500,0 млн.сум тәшкил итә.<br>Комплекслы проект чараларын финанслашу:<br><br>Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә федераль бюджет акчасы – 2 700,0 млн.сум, шул исәптән:<br>2010 ел – 400,0 млн.сум;<br>2011 ел – 400,0 млн.сум;<br>2012 ел – 400,0 млн.сум;<br>2013 ел – 400,0 млн.сум;<br>2014 ел – 380,0 млн.сум;<br>2015 ел – 360,0 млн.сум;<br>2016 ел – 360,0 млн.сум;<br><br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 2 800,0 млн.сум, шул исәптән:<br>2010 ел – 400,0 млн.сум;<br>2011 ел – 400,0 млн.сум;<br>2012 ел – 400,0 млн.сум;<br>2013 ел – 400,0 млн.сум;<br>2014 ел – 400,0 млн.сум;<br>2015 ел – 400,0 млн.сум;<br>2016 ел – 400,0 млн.сум;<br>«Россия мәдәнияте» федераль максатчан программасының оештыру-финанс чаралары планын һәм конкурс буенча сайлап алынган проектлар нигезендә башка мәдәниятне үстерү программаларын тормышка ашыру кысаларында, федераль милектә булган федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын реставрацияләүгә бирелә торган федераль бюджет акчасы;<br>Зеленодольск һәм Спас муниципаль районнары бюджетларының күздә тотылган акчасы;<br>«Яңарыш» Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен торгызу республика фонды» коммерциячел булмаган оешмасының, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасының, Татарстан Республикасы Газлаштыру фондының, хосусый милектә булган мәдәни мирас объектлары милекчеләренең күздә тотылган акчалары;<br>юридик һәм физик затларның ирекле иганәләре, инвесторлар акчасы. |

| | |
|---|---|
| | 2010 – 2016 елларга комплексы проектның «Тарихи һәм мәдәни мирасның сакланышын тәэмин итү: ремонт-реставрация эшләре, шул исәптән хәзерге көндә файдалану өчен мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне) консервацияләү, ремонтлау, реставрацияләү һәм җайлаштыру, шулай ук мәдәни мирас объектларында фәнни-тикшеренү, тикшеренү, проект һәм җитештерү эшләре, фәнни-методик җитәкчелек, техник күзәтчелек һәм автор күзәтчелеге» ярдәмче проектындагы V – VIII бүлекләр чараларын финанслауга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы күләме, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып, тиешле елга Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнә |
| Комплексы проект-ның максатчан күр-сәткечләре (индика-торлары) | Түбәндәгеләрне арттыру:<br>тикшерелгән археологик мирас объектлары мәйданын (61 279 кв.метрга кадәр);<br>реставрация тәмамланган мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) санын (58 берәмлеккә кадәр);<br>археологик коткару кыр эшләре үткәрелгән территория мәйданын (51 595 кв.метрга кадәр);<br>реставрацияләнгән музей фонды берәмлекләре санын (7 010 берәмлеккә кадәр);<br>экспозиция мәйданнарын (5 987 кв.метрга кадәр);<br>музей предметлары һәм коллекцияләре санын (3 694 берәмлеккә кадәр);<br>комплексы (интеграцияләнгән) куркынычсызлык, элемтә һәм идарә системасы белән җиһазландырылган мәдәни объектлар санын (32 берәмлеккә кадәр);<br>ремонтланган юллар озынлыгын (6 058 метрга кадәр);<br>транспорт инфраструктурасы объектлары санын (12 берәмлеккә кадәр);<br>төзекләндерелгән территорияләр мәйданын (21 235 кв.метрга кадәр) |
| Комплексы проект үтәлешен тикшерүдә тотуны оештыру системасы | Комплексы проект үтәлешен тикшерүдә тоту Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла |

## 1. Кереш

2010 – 2016 елларга «Мәдәни мирас – Свияжск утрау-шәһәре һәм борынгы Болгар» комплекслы проекты (алга таба – Комплекслы проект) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 29 декабрендәге 01-2607 нче мөрәҗәгате буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисенең 2009 елның 30 декабрендәге ВП-П44-7911 нче йөкләмәсе һәм Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 2010 елның 16 гыйнварындагы П/01-490 нчы йөкләмәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары нигезендә эшләнде.

Татарстан Республикасы Президентының 2008 ел, 3 июль, ПУ-312 нче Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт милли сәясәте концепциясе нигезендә, Комплекслы проект Свияжск утрау-шәһәренең һәм борынгы Болгарның уникаль мәдәни мирасын өйрәнү, саклауның, алардан рациональ файдалануның һәм киләчәк буыннар өчен аларны популярлаштыруның, алга таба мәдәни, фәнни-агарту, хаҗ һәм туристлык функцияләрен үстерүнең, тарихи җирлекләрдә яхшы сыйфатларда яшәү, эшләү һәм ял итү өчен шартлар тудыруның эчтәлеген һәм төп юлларын билгели һәм, тиешле федераль, төбәк (республика) һәм ведомстволар программалары белән берләштерүдә, һәр гражданның мәдәни кыйммәтләрдән файдалана алуга конституцион хокукын, халыкларның үз мәдәни-милли үзенчәлеген саклауга һәм үстерүгә хокукларын тормышка ашыруга, җәмгыятьне тәңгәлләштерү һәм аның рухи-әхлакый бердәмлеге нигезе буларак мәдәниятнең барлыкка килүе һәм үсеше турында мәгълүмат чыганакларын саклау һәм саклап калуга йөз тоткан.

Дәүләт сәясәтенең аерым бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән Комплекслы проект чараларын һәм Свияжск утрау-шәһәренең һәм борынгы Болгарның мәдәни мирасын саклау, алга таба мәдәни, фәнни-агарту, хаҗ һәм туристлык функцияләрен үстерү, әлеге тарихи җирлекләрдә яхшы сыйфатларда яшәү, эшләү һәм ял итү урыннары өчен шартлар тудыру өлкәсендәге эшчәнлекнең өстенлекләрен финанслау федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, муниципаль бюджетлар акчасы, шулай ук бюджеттан тыш керемнәр исәбеннән гамәлгә ашырылачак.

Свияжск утрау-шәһәренең һәм борынгы Болгарның мәдәни мирасын тәшкил иткән күренешләр төрлелеге булган проблемаларны аерым рәвештә, әлеге территорияләрнең социаль-икътисадый мәсьәләләрен хәл итмичә, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый оешмалар һәм башка эшчәнлек субъектларының киң хезмәттәшлек итүеннән башка хәл итәргә мөмкинлек бирми, проект (программа) ысулларын куллану ихтыяҗын тудыра.

## 2. Проблеманың эчтәлеге һәм аны проект (программа) ысуллары белән хәл итү ихтыяҗын нигезләү

2.1. Борынгы Болгар.

Стратегик һәм сәүдә мөнәсәбәтләрендә Көнчыгыш Европадагы иң мөһим урыннарның берсендә, Кама һәм Идел елгалары кушылган җирдә урнашкан Болгар шәһәре барлыкка килгән көненнән бирле Идел буе халыклары тарихында гына түгел, бөтен Көнчыгыш Европа тарихында мөһим роль уйнаган: X – XI гасырларда ул Көнчыгыш Европаның иң эре беренче феодал дәүләтләренең берсе – Идел буе Болгар дәүләте башкаласы, XIII – XIV гасырларда – Алтын Урданың (Батый-хан ставкасы) беренче башкаласы булган.

1969 елда, борынгы шәһәр ядкәрьләрен саклауны көчәйтү максатларында, «Болгар дәүләт тарих-архитектура тыюлыгы» дәүләт учреждениесе (2000 елдан – Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы) төзелә. 1999 елда Болгар тарих-архитектура комплексы ЮНЕСКО Бөтендөнья мәдәни мирасының Башлангыч исемлегенә (Көтү исемлеге) кертелә. ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитетының 38 нче сессиясе карары белән 2014 елның 23 июнендә Доха шәһәрендә (Катар дәүләте) Болгар тарих-археология комплексы ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелә. Әлеге 38 COM 8B.43 нче карарда идарә планын эшләп бетерергә, объект сакланышының торышын күзәтү һәм тиешле мәгълүматны документлаштыру өчен төгәл күрсәткечләрдән файдалануны кертеп, мониторинг системасын эшләргә, объектның күләмле архивын һәм объектка якын рәвештә барлык мәгълүматлар һәм хисаплар, шулай ук археологик табылдыклар үзәкләштерелеп тупланачак саклау урыны төзергә киңәш ителә.

2.2. Свияжск утрау-шәһәре.

1551 елның 24 маенда Явыз Иван патшаның турыдан-туры җитәкчелегендә нигез салынган Свияжск Россия дәүләте формалашуның тарихи процессларында төбәкнең хәрби-административ, православие, һөнәрчелек-сәүдә үзәге буларак мөһим роль уйнаган һәм Идел буе халыклары арасында рус рухи мәдәнияте таралуга зур йогынты ясаган.

1999 елда Свияжск тарих-архитектура һәм сәнгать комплексы ЮНЕСКО Бөтендөнья мәдәни мирасының Башлангыч исемлегенә (Көтү исемлеге) кертелә. 2009 елда «Свияжск утрау-шәһәре» истәлекле урыны буларак Свияжск мәдәни мирас объектларына карый башлый. «Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе төзелә, 2015 елда аның исеме «Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе дип үзгәртелә.

Россия Федерациясе Дәүләт Советының һәм Россия Федерациясе Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать буенча советның 2014 елның 24 декабрендәге берләштерелгән утырышы йомгаклары буенча Россия Федерациясе Президенты йөкләмәләре исемлегенең (2015 ел, 22 гыйнвар, Пр-93 нче) 3 нче пунктындагы «д» пунктчасы нигезендә Свияжск объектларын ЮНЕСКО Бөтендөнья мәдәни мирасы исемлегенә кертү эше алып барыла.

2.3. Хәзерге көндә Свияжск утрау-шәһәре һәм борынгы Болгар территориясендә федераль һәм төбәк (республика) әһәмиятендәге 65 мәдәни мирас объекты дәүләт

саклавында тора.

Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы фондлары 102 913 саклана торган берәмлек тәшкил итә, шул исәптән: 14 833 нумизматика предметы, 66 106 археология предметы, 1 493 кулланма сәнгать һәм этнография эшләнмәсе, 30 берәмлек корал, 151 рәсем сәнгате эшләнмәсе, 252 графика эшләнмәсе, 13 скульптура эшләнмәсе, 19 568 документ, сирәк китап, 55 табигый-фәнни коллекция предметы, 59 техника тарихы предметы, 353 башка предмет. Шулардан 2 234 предмет кыйммәтле металлар һәм асылташлардан тора.

«Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы фондларында 460 берәмлек саклана, шул исәптән: 20 нумизматика предметы, 96 кулланма сәнгать һәм этнография эшләнмәсе, 4 берәмлек корал, 45 рәсем сәнгате эшләнмәсе, 14 графика эшләнмәсе, 2 скульптура эшләнмәсе, 257 документ, сирәк китап, 1 табигый-фәнни коллекция предметы, 2 техника тарихы предметы.

2.4. Свияжск утрау-шәһәре һәм борынгы Болгарның хәзерге торышы тарих, археология, архитектура, шәһәр төзелеше, сәнгать, фән һәм техника, эстетика, этнология яки антропология, социаль мәдәният ягыннан кыйммәткә ия объектларны өйрәнүгә, шулай ук гореф-гадәтләрне, йолаларны һәм бәйрәмнәрне саклауга һәм алга таба үстерүгә, хәзерге көндә файдалану өчен мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне) ремонтлау, консервацияләү, реставрацияләү һәм җайлаштыруга, мәдәни мирас предметларын реставрацияләү һәм консервацияләүгә, музей фондын тулыландыруга, «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» һәм «Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуга, торак, туристлык-хаҗ, транспорт һәм инженерлык инфраструктураларын үстерүгә, әлеге уникаль территорияләрне төзекләндерүгә йөз тоткан чаралар комплексын үтәүгә бәйле.

2.5. «Россия мәдәнияте (2006 – 2010 еллар)» федераль максатчан программасы, 2005 – 2010 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасы, 2007 – 2009 елларга «Мирас – Наследие» мәдәни мирасны саклау буенча максатчан комплекслы программа чараларын, Тарихи кече шәһәр буларак Свияжскны социаль-икътисадый, экологик һәм архитектура-сәнгати яңарту концепциясенең төп юнәлешләрен һәм Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгын үстерү буенча перспективалы планны тормышка ашыру кысаларында бирелгән акчага карамастан, мәдәни мирас объектлары һәм предметлары шактый күп күләмдә саклауга мохтаҗ.

2.6. Свияжск утрау-шәһәренең һәм борынгы Болгарның күпчелек архитектура объектлары хәзерге көндә файдалану өчен аларны реставрацияләү, консервацияләү, ремонтлау, торгызу һәм җайлаштыру буенча тулы чаралар комплексы үткәрүгә мохтаҗ. Соңгы ун ел дәвамында аларның физик сакланышын агымдагы тәэмин итү башкарылмады диярлек. Свияжск утрау-шәһәренең күпчелек торак һәм граждан архитектурасы объектларында беркайчан ремонт-реставрация эшләре үткәрелмәгән.

2.7. Болгар шәһәрлегендәге археологик тикшеренүләр интенсивлыгы 1980 еллар ахырыннан, аеруча 1990 еллар уртасыннан сизелерлек дәрәҗәдә кимеде. Свияжск утрау-шәһәре һәм борынгы Болгар архитектура мирасының хәрабәгә әверелгән

истәлекләрен тикшерүгә, аларны консервацияләү һәм алга таба музейлаштыруга тиешенчә игътибар бирелмәде.

2.8. «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе музей фондының дәүләт өлешен комплектлаштыру һәм саклау җитди проблема булып кала бирә. Базар шартларында музейлар милли байлыкны тәшкил иткән тарихи һәм мәдәни ядкәрләр һәм сәнгать әсәрләре сатып алуда конкурентлык сәләтенә ия түгел. Музей предметлары систематалы рәвештә реставрацияләнми. «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе музей фондының 80 процентка якын дәүләт өлеше төрле дәрәҗәдәге консервацияләү һәм ярдәмче реставрацияләүгә мохтаҗ.

2.9. Свияжск монастырьлары, Свияжск өяз шәһәре һәм Свияжск өязе тарихы һәм мәдәнияте белән бәйле аеруча кыйммәткә ия мирас (документаль, предмет-күнкүреш, сәнгати) социаль-сәяси, икътисадый һәм демографик сәбәпләр аркасында таркалган, бер өлеше югалган.

2.10. «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе эшчәнлегендә матди-техник база, музей фонды куркынычсызлыгы һәм аны саклау системасы камил түгел, туристлыкның үсеш алган инфраструктурасы юк (урнаштыру чаралары, транспорт, җәмәгать туклануы, күңел ачу һ.б.).

2.11. Свияжск утрау-шәһәре һәм борынгы Болгар истәлекләрен саклау һәм «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» һәм «Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләрен алга таба үстерү мәсьәләләре турыдан-туры Болгар шәһәре һәм Спас муниципаль районының, Свияжск авылының (Свияжск авыл җирлегенең административ үзәге) инфраструктурасы һәм туристлык сервисы үсеш алмаган булуның гомуми проблемаларына бәйле.

2.12. Алда бәян ителгәннәр барысы да тарихи җирлекләрнең тиешле торак, транспорт, инженерлык һәм туристлык инфраструктураларын төзүгә бәйле проект (программа) ысуллары белән мәдәни мирасны саклау, рациональ файдалану һәм популярлаштыру буенча проблемалар комплексын хәл итүгә йөз тоткан эшне дәвам итәргә кирәклеге турында сөйли.

## 3. Комплекслы проектның төп максаты, бурычлары, чаралары, иң мөһим максатчан күрсәткечләре һәм аны тормышка ашыру вакытлары

Россиянең уникаль истәлекле урыннары – Свияжск утрау-шәһәренең һәм борынгы Болгарның сакланышын һәм алардан нәтиҗәле файдалануны, аларны рухи, социаль-икътисадый һәм мәдәни торгызуны тәэмин итү Комплекслы проектның төп максаты булып тора.

Комплекслы проектны тормышка ашыру вакытлары: 2010 – 2016 еллар.

**2010 – 2016 елларга**
**«Мәдәни мирас – Свияжск утрау-шәһәре һәм борынгы Болгар»**
**комплекслы проекты бурычларын тормышка ашыру буенча чаралар**
**исемлеге**

| Бурычлар | Чаралар | Үтәү вакытлары | Максатчан күрсәткечләр (индикатор-лар), үлчәү берәмлеге | Индикаторларның мәгънәләре | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2009 ел (база) | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Яңа археологик объектларны бил-геләү һәм турист-лык-экскурсия күргәзмәсенә кертү | Тарихи-мәдәни геомәгълүмати си-стемалар төзү, «Виртуаль шәһәр» 3D-моделен төзү<br><br>архитектура-архе-ология тикшере-нүләре<br><br>«Виртуаль шәһәр» моделен төзеп, җимерми торган ысуллар белән ар-хеология истә-лекләрен тикшерү | 2011 – 2016 еллар<br><br>2010 – 2016 еллар<br><br>2011 – 2016 еллар | тикшерелгән археологик мирас объект-лары мәйда-нын арттыру, кв.метр | 20 000 | 20 150 | 21 750 | 24 250 | 30 150 | 36 650 | 45 150 | 61 279 |
| Мәдәни мирас объ-ектларының һәм музей фонды-ның аеруча кыйм-мәткә ия предмет-лары | Проект-смета до-кументларын эш-ләү, проект-смета документларына экспертиза үткәрү | 2010 – 2016 еллар | реставрация тәмамланган мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм | 0 | 0 | 14 | 19 | 20 | 22 | 55 | 58 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| һәм коллекцияләренең физик торышын яхшырту | кичектергесез һәлакәткә каршы һәм консервацияләү эшләре үткәрү | 2010 – 2016 еллар | мәдәни истәлекләр) санын арттыру, берәмлек | | | | | | | | |
| | археологик объектларны музейлаштыру | 2010 – 2016 еллар | | | | | | | | | |
| | тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне, шул исәптән дини оешмаларга файдалануга бирелгән культ әһәмиятендәгеләрен саклау буенча тулы эшләр комплексын тормышка ашыру, мәдәни мирас объектлары территорияләрен төзекләндерү, яшелләндерү, кое урнаштыру | 2010 – 2016 еллар | | | | | | | | | |
| | торак буларак файдаланыла торган тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне саклау эшләре үткәрү | 2010 – 2016 еллар | | | | | | | | | |
| | мәдәни мирас объектларын мәдәни-агарту һәм турист- | 2010 – 2016 еллар | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | лык максатларында файдалану өчен җайлаштыру | | | | | | | | | | |
| | Археологик коткару эшләре үткәрү | 2010 – 2016 еллар | археологик коткару кыр эшләре үткәрелгән территория мәйданын арттыру, кв.метр | 6 000 | 22 000 | 31 700 | 38 200 | 42 200 | 45 200 | 48 200 | 51 595 |
| | Музей фондының аеруча кыйммәткә ия предметлары һәм коллекцияләренең физик торышын яхшырту буенча эшләр комплексын гамәлгә ашыру | 2010 – 2016 еллар | реставрацияләнгән музей фонды берәмлекләре санын арттыру | 20 | 70 | 137 | 1 387 | 2 020 | 2 520 | 3 020 | 7 010 |
| Музей фонды предметлары һәм коллекцияләреннән һәркем файдалана алырлык булуны тәэмин итү | Экспозиция мәйданнарын киңәйтү | 2010 – 2016 еллар | экспозиция мәйданнарын арттыру, кв.метр | 200 | 700 | 1 700 | 2 200 | 2 700 | 3 700 | 4 200 | 5 987 |
| | Яңа музей экспозицияләре булдыру | 2010 – 2016 еллар | музей предметлары һәм коллекцияләре санын арттыру, берәмлек | 694 | 894 | 1 122 | 1 823 | 2 194 | 2 694 | 3 194 | 3 694 |
| | Мәдәният уч- | 2010 – 2016 | комплексы | 2 | 5 | 8 | 11 | 14 | 17 | 22 | 32 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | реждениеләренең куркынычсызлыгын тәэмин итү | еллар | (интеграцияләнгән) куркынычсызлык, элемтә һәм идарә системасы белән җиһазландырылган мәдәни объектлар санын арттыру | | | | | | | | |
| Кешеләрнең яшәве һәм туристлык тармагын нәтиҗәле үстерү өчен уңай шартлар тудыру | Автомобильләр (керү) юлларын һәм поселок эчендәге юлларны төзекләндерү һәм ремонтлау | 2010 – 2012 еллар | ремонтланган юллар озынлыгын арттыру, метр | 0 | 1 242 | 1 242 | 6 058 | 6 058 | 6 058 | 6 058 | 6 058 |
| | Автомобиль кую урыннарын оештыру<br>Елга вокзалларын төзекләндерү | 2010 – 2016 еллар | транспорт инфраструктурасы объектлары санын арттыру, берәмлек | 0 | 0 | 6 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 |
| | Инженерлык инфраструктурасын үстерү | 2010 – 2012 еллар | | | | | | | | | |
| | Территорияләрне төзекләндерү | 2010 – 2016 еллар | төзекләндерелгән территорияләр мәйданын арттыру, кв.метр | 0 | 0 | 0 | 315 | 1 125 | 1 560 | 4 735 | 21 235 |

## 4. Комплекс== проектны ресурслар белән тәэмин итү

Комплексл проектны финанслау федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджетлар акчасы, шул исәптән бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән финанслашу рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Комплексл проект чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 5 500,0 млн.сум тәшкил итә.

Комплексл проект чараларын финанслашу:

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә федераль бюджет акчасы – 2 700,0 млн.сум, шул исәптән:

2010 ел – 400,0 млн.сум;
2011 ел – 400,0 млн.сум;
2012 ел – 400,0 млн.сум;
2013 ел – 400,0 млн.сум;
2014 ел – 380,0 млн.сум;
2015 ел – 360,0 млн.сум;
2016 ел – 360,0 млн.сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 2 800,0 млн.сум, шул исәптән:

2010 ел – 400,0 млн.сум;
2011 ел – 400,0 млн.сум;
2012 ел – 400,0 млн.сум;
2013 ел – 400,0 млн.сум;
2014 ел – 400,0 млн.сум;
2015 ел – 400,0 млн.сум;
2016 ел – 400,0 млн.сум;

«Россия мәдәнияте» федераль максатчан программасының оештыру-финанс чаралары планын һәм конкурс буенча сайлап алынган проектлар нигезендә башка мәдәниятне үстерү программаларын тормышка ашыру кысаларында, федераль милектә булган федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын реставрацияләүгә бирелә торган федераль бюджет акчасы;

Зеленодольск һәм Спас муниципаль районнары бюджетларының күздә тотылган акчасы;

«Яңарыш» Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен торгызу республика фонды» коммерциячел булмаган оешмасының, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасының, Татарстан Республикасы Газификация фондының, хосусый милектә булган мәдәни мирас объектлары милекчеләренең күздә тотылган акчалары;

башка чыганаклар.

2010 – 2016 елларга комплексл проектның «Тарихи һәм мәдәни мирасның сакланышын тәэмин итү: ремонт-реставрация эшләре, шул исәптән хәзерге көндә файдалану өчен мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне) кон-

сервацияләү, ремонтлау, реставрацияләү һәм җайлаштыру, шулай ук мәдәни мирас объектларында фәнни-тикшеренү, тикшеренү, проект һәм җитештерү эшләре, фәнни-методик җитәкчелек, техник күзәтчелек һәм автор күзәтчелеге» ярдәмче проектындагы V – VIII бүлекләре буенча финанслауга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы күләме, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып, тиешле елга Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнә.

## 5. Комплекслы проектны тормышка ашыру механизмы

Комплекслы проект Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларында, билгеләнгән тәртиптә төзелә торган субсидия бирү турындагы килешүләрдә күздә тотылган тәртиптә тормышка ашырыла.

Комплекслы проектны федераль бюджет акчасы исәбеннән финанслау Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан ел саен раслана торган Комплекслы проектны тормышка ашыру буенча чараларны финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр бирү кагыйдәләренә ярашлы рәвештә, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелә торган субсидия бирү турындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Чираттагы финанс елына расланган ассигнованиеләр нигезендә Комплекслы проектны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау законнарда билгеләнгән тәртиптә техник заказчы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Комплекслы проектта билгеләнгән бурычларны хәл итү дәрәҗәсенең төп күрсәткечләре бюджет финанславы субъектлары эшчәнлегенең нәтиҗәләре һәм төп юнәлешләре турындагы еллык докладларга кертелә.

Комплекслы проектны тормышка ашыру барышында, Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында икътисадый һәм башка шартлар үзгәрү мөмкинлеген һәм мониторингны исәпкә алып, аңа хәленә карап төзәтмәләр кертелүе күздә тотыла.

## 6. Комплекслы проектны тормышка ашыру белән идарә итүне оештыру һәм аның барышын тикшерүдә тоту

Чараларның масштаблыгын һәм катлаулылыгын исәпкә алып, шулай ук Комплекслы проектны тормышка ашыру белән рациональ идарә итү максатларында, ул ярдәмче проектларга бүленгән.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тулаем Комплекслы проектны тормышка ашыру өчен җавап бирә, проект чараларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру, федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалану буенча килешенгән гамәлләрне тәэмин итә, чираттагы финанс елына Комплекслы проектны финанслау өчен федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан ассигнованиеләргә җыелма

бюджет заявкасын эшли һәм билгеләнгән тәртиптә кертә, шулай ук хисап елына Комплекслы проектны тормышка ашыру барышы хакында хисап әзерли.

Федераль бюджет акчасы исәбеннән Комплекслы проектны тормышка ашыру хакындагы хисаплар Комплекслы проектны тормышка ашыру буенча чараларны финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидия бирү кагыйдәләре һәм Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелә торган субсидия бирү турындагы килешү нигезендә әзерләнә.

Техник заказчы проект чаралары үтәлеше барышы белән идарә итү, анализлау һәм тикшерүдә тоту өчен мәгълүмати технологияләр кертүне оештыра.

Дәүләт заказчысы – Комплекслы проектны яраштыручы аны тормышка ашыру турында статистика хисаплылыгы алып баруны оештыра, шулай ук Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына проект эшләре барышы һәм финанс чараларыннан файдалану нәтиҗәлелеге хакындагы докладларны җибәрә.

Дәүләт заказчысы – Комплекслы проектны яраштыручы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә, билгеләнгән тәртиптә аны тормышка ашыру барышына эксперт тикшерүләре оештыра.

Комплекслы проект үтәлешен тикшерүдә тотуны дәүләт һәм ведомстволар хисаплылыгы һәм төзелә торган шартнамәләр (контрактлар, килешүләр) нигезендә билгеләнгән тәртиптә дәүләт заказчысы – Комплекслы проектны яраштыручы гамәлгә ашыра.

Тикшерүдә тоту проект чараларын тормышка ашыру һәм үтәүчеләрнең аларга бирелә торган финанс чараларыннан рациональ файдалануы турында, тормышка ашырыла торган проект чараларының сыйфаты, шартнамәләрне (контрактларны, килешүләрне) үтәү вакытлары хакында вакытлы хисаплылыкны үз эченә ала.

Проект чараларын үтәүчеләр бирелгән акчадан максатчан файдалану турында билгеләнгән тәртиптә хисап бирә.

## 7. Комплекслы проектны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү

Комплекслы проектны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү гомумиләштерелгән бәяләү күрсәткечләре (индикаторлары) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Комплекслы проектның максаты буенча, аны тормышка ашыру Россиянең уникаль истәлекле урыннары – Свияжск утрау-шәһәренең һәм борынгы Болгарның сакланышын һәм алардан нәтиҗәле файдалануны, аларны рухи, социаль-икътисадый һәм мәдәни торгызуны тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Комплекслы проектны тормышка ашыру чорында, мәдәни мирасны саклау, «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» һәм «Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениеләре эшчәнлеген камилләштерү белән беррәттән, әлеге тарихи территорияләрдәге тормыш сыйфаты шактый дәрәҗәдә яхшыртылачак, шулай ук туристлык базарында Татарстан Республикасының танылуын һәм уңай имиджын тәэмин иткән конкурентлыкка сәләтле төбәк

туристлык продукты формалаштырылачак.

Ремонт-реставрация эшләре нәтиҗәсендә федераль һәм төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне), шул исәптән дини оешмаларга файдалануга бирелгән культ әһәмиятендәге истәлекләрне саклап калу тәэмин ителәчәк.

Хәзерге көндә мәдәни-агарту (музей) максатларында файдалану өчен өстәмә рәвештә 10нан артык мәдәни мирас объекты (тарихи һәм мәдәни ядкәр) җайлаштырылачак, шул исәптән Казна корылмаларының биналар комплексы, Сәүдәгәр Каменев йорты, гарипләр йорты, инженерлык корпусы казармалары, суэтем башнясы – Свияжскта, Төньяк һәм Көнчыгыш мавзолейлары, Кара пулат һәм Хан төрбәсе – Болгарда.

Мәдәни мирас объектларының кайберләре археологик тикшеренү һәм консервацияләүдән соң музейлаштырылачак (Свияжскта – Рождествено соборы, София, Никола, Благовещение чиркәүләре хәрабәләре, Мәскәү урамының XVI – XVIII йөзләрдә торак йортлар салынган урыннары фрагментлары, Болгарда – Кызыл пулат, Көнчыгыш пулаты («Хан пулатлары, яки мунча»), Манаралы йортлар («Хан сарае»), Кеше шәһәрчекнең Көньяк бинасы, мавзолейлар, шәһәр базары һ.б.).

Музей фондын тулыландыру һәм реставрацияләү гамәлдәге һәм яңа музей экспозицияләрен шактый киңәйтәчәк.

Саклык-янгын сигнализациясе, видеокүзәтү, «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» һәм «Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениеләре биналарына һәм территорияләренә керүне тикшерүдә тоту һәм аның белән идарә итү системаларын үз эченә алган комплекслы (интеграцияләнгән) куркынычсызлык, элемтә һәм идарә системасы төзеләчәк.

Болгар шәһәрлегенең үзәк өлешендә урнашкан агач торак йортлар сүтеләчәк, Свияжсктагы Иоанн-Предтеча монастыренең братлар корпусларында яшәүчеләр күчереләчәк. Анда яшәүчеләр өчен югары дәрәҗәдәге уңайлыклар булган күпфатирлы торак һәм индивидуаль торак йортлар төзеләчәк.

Яңа транспорт, инженерлык, музей һәм туристлык инфраструктурасы формалаштырылачак: Болгарда – туристлар теплоходлары өчен причал, «Болгар цивилизациясе музее» музей функциясе булган елга вокзалы, хаҗилар өчен палаткалы лагерь, Икмәк музее, мәчет һәм мәдрәсә комплексы, Идел буе Болгар дәүләте 922 елда ислам динен рәсми кабул итүгә багышланган истәлекле билге (ядкәр), Свияжскта туристлар теплоходлары өчен причал, туристлар кабул итү өчен автостанция белән берләштерелгән елга вокзалы комплексы, Свияжск шәһәренең тарих музее, елга музее, кунакханәләр төзеләчәк.

Комплекслы проектны тормышка ашыру Татарстан Республикасының һәм Россиядәге башка төбәкләрнең хуҗалык алып баручы субъектларын өлешчә җәлеп итәргә (проект, фәнни, төзелеш һәм реставрация оешмалары һәм учреждениеләре), эш урыннары санын арттырырга, вакытлыча (сезонлы) эш урыннары булдырырга, шулай ук туристлык индустриясенә инвестицияләр өчен уңай шартлар тудырырга мөмкинлек бирәчәк.

## 8. Комплекслы проект чаралары системасы

Комплекслы проектта түбәндәге ике ярдәмче проект кысаларында куелган бурычларны хәл итүгә йөз тоткан чаралар комплексын эшләү һәм тормышка ашыру күздә тотыла:

1) «Тарихи һәм мәдәни мирасны өйрәнү һәм популярлаштыру»;

2) «Тарихи һәм мәдәни мирасның сакланышын тәэмин итү: ремонт-реставрация эшләре, шул исәптән хәзерге көндә файдалану өчен мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне) консервацияләү, ремонтлау, реставрацияләү һәм җайлаштыру, шулай ук мәдәни мирас объектларында фәнни-тикшеренү, тикшеренү, проект һәм җитештерү эшләре, фәнни-методик җитәкчелек, техник күзәтчелек һәм автор күзәтчелеге».

### 8.1. «Тарихи һәм мәдәни мирасны өйрәнү һәм популярлаштыру» ярдәмче проекты.

Ярдәмче проектны тормышка ашыру буенча чаралар системасында түбәндәгеләр күздә тотыла:

тарихи-мәдәни геомәгълүмати системалар төзү, «Виртуаль шәһәр» 3D-моделен төзү;

архитектура-археология тикшеренүләре;

«Виртуаль шәһәр» моделен төзеп, җимерми торган ысуллар белән археология истәлекләрен тикшерү;

истәлекләрне саклау зоналары проектларын эшләү;

музей күргәзмәсе концепциясен эшләү;

нәшер итү эшчәнлеге;

килүчеләрне исәпкә алу системасын төзү.

### 8.2. «Тарихи һәм мәдәни мирасның сакланышын тәэмин итү: ремонт-реставрация эшләре, шул исәптән хәзерге көндә файдалану өчен мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне) консервацияләү, ремонтлау, реставрацияләү һәм җайлаштыру, шулай ук мәдәни мирас объектларында фәнни-тикшеренү, тикшеренү, проект һәм җитештерү эшләре, фәнни-методик җитәкчелек, техник күзәтчелек һәм автор күзәтчелеге» ярдәмче проекты.

Ярдәмче проектны тормышка ашыру буенча чаралар системасында түбәндәгеләр күздә тотыла:

проект-смета документларын эшләү, проект-смета документларына экспертиза үткәрү;

археологик коткару эшләре үткәрү;

кичектергесез һәлакәткә каршы һәм консервацияләү эшләре үткәрү;

археологик объектларны музейлаштыру

тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне, шул исәптән дини оешмаларга файдалануга бирелгән культ әһәмиятендәге истәлекләрне саклау буенча реставрация эшләренең тулы комплексын тормышка ашыру, мәдәни мирас объектлары территорияләрен төзекләндерү, яшелләндерү, кое урнаштыру;

торак буларак файдаланыла торган тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне саклау

буенча ремонт эшләре үткәрү;

мәдәни-агарту һәм туристлык максатларында файдалану өчен мәдәни мирас объектларын җайлаштыру;

мәдәни мирас объектларын саклауга, аларны киләчәктә милеккә биреп, хосусый инвестицияләр җәлеп итү;

музей фондының аеруча кыйммәткә ия предметлары һәм коллекцияләренең физик торышын яхшырту буенча эшләр комплексын гамәлгә ашыру;

мәдәният учреждениеләренең куркынычсызлыгын тәэмин итү;

экспозиция мәйданнарын киңәйтү;

яңа музей экспозицияләре булдыру;

елга вокзалларын төзекләндерү;

автомобильләр (керү) юлларын һәм поселок эчендәге юлларны төзү, төзекләндерү һәм ремонтлау;

автомобиль кую урыннарын оештыру;

инженерлык инфраструктурасын үстерү.

## 9. Комплекслы проектны тормышка ашыру буенча чаралар планы

### 9.1. «Тарихи һәм мәдәни мирасны өйрәнү һәм популярлаштыру» ярдәмче проекты

| Т/с | Чараның исеме | Үтәү вакыты |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Болгар шәһәрлеге территориясендәге объектларда аларны алга таба музейлаштыру максатларында архитектура-археология тикшеренүләрен үткәрү, шул исәптән:<br>Кызыл пулатны, XVI йөз<br>Манаралы йортны («Хан сарае»), 1240 еллар (хәрабәләр)<br>XVI йөз мавзолейларын;<br>Кече шәһәрчекнең көньяк бинасын, XVI йөз<br>шәһәр базарын, XIII – XIV йөзләр;<br>җәмигъ мәчете янындагы бинаны<br>2 нче, 3 нче мунчаларны<br>чүлмәк ясый торган учак урыннарын | 2010 – 2016 еллар |
| 2. | «Свияжск утрау-шәһәре» истәлекле урыны территориясендәге объектларда аларны алга таба музейлаштыру максатларында архитектура-археология тикшеренүләрен үткәрү, шул исәптән:<br>Рождествено соборы, София, Никола, Благовещение чиркәүләре хәрабәләрен<br>Мәскәү урамының XVI – XVIII йөзләрдә торак йортлар салынган урыннары фрагментларын<br>Татар бистәчеген<br>посадтагы агач шәһәр йортларын | 2010 – 2016 еллар |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 3. | «Виртуаль шәһәр» моделен төзеп, җимерми торган ысуллар белән (гео-, авиакосмик һәм магнит тикшерүләре) Болгар шәһәрлеге территориясенә тоташ тикшерү үткәрү | 2011 – 2016 еллар |
| 4. | Болгар шәһәрлегенең, «Свияжск утрау-шәһәре» истәлекле урыны һәм аның янындагы территорияләрнең тарихи-мәдәни геомәгълүмати системасын төзү | 2011 – 2016 еллар |
| 5. | Даталарны билгеләү һәм борынгы технологияләрне төзекләндерү буенча археология объектларын өйрәнүнең яңа ысулларын булдыру һәм кертү | 2011 – 2016 еллар |
| 6. | Болгар шәһәрлеген саклау зоналары проектын эшләү | 2012 ел |
| 7. | «Свияжск утрау-шәһәре» истәлекле урынын саклау зоналары проектын эшләү | 2012 ел |
| 8. | Болгар шәһәрлеге музей күргәзмәсе концепциясен эшләү | 2013 – 2015 еллар |
| 9. | «Свияжск утрау-шәһәре» истәлекле урынының музей күргәзмәсенең концепциясен эшләү | 2013 – 2015 еллар |
| 10. | Болгар шәһәрлеге территориясендә җимерми торган ысуллар белән археология тикшеренүләре үткәрү | 2015 – 2016 еллар |
| 11. | Болгар шәһәрелегенең һәм «Свияжск утрау-шәһәре» истәлек-ле урынының мәдәни мирас объектларында фәнни-тикшеренү эшләре | 2015 – 2016 еллар |
| 12. | Нәшер итү эшчәнлеге | 2016 ел |

**9.2. «Тарихи һәм мәдәни мирасның сакланышын тәэмин итү: ремонт-реставрация эшләре, шул исәптән хәзерге көндә файдалану өчен мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне) консервацияләү, ремонтлау, реставрацияләү һәм җайлаштыру, шулай ук мәдәни мирас объектларында фәнни-тикшеренү, тикшеренү, проект һәм җитештерү эшләре, фәнни-методик җитәкчелек, техник күзәтчелек һәм автор күзәтчелеге» ярдәмче проекты**

| Т/с | Чараның исеме | Үтәү вакыты |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| I бүлек. Болгар шәһәрлеге территориясендә XIII – XIX йөзләрдәге архитектура истәлекләрен хәзерге көндә файдалану өчен ремонтлау, реставрацияләү, һәлакәттән саклау, консервацияләү һәм җайлаштыру эшләре | | |
| 1.1. | Җәмигъ мәчете («Дүртпочмаклык») XIII-XIV йөзләр | 2010 – 2016 еллар |
| 1.2. | Төньяк мавзолее («Монастырь кар базы»), XIV йөз | 2010 – 2016 еллар |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 1.3. | Көнчыгыш мавзолее («Святой Николай чиркәве»), XIV йөз | 2010 – 2016 еллар |
| 1.4. | Успение Пресвятой Богородицы чиркәве, 1732 – 1734 еллар | 2010 – 2016 еллар |
| 1.5. | Кара пулат, XIV йөз | 2010 – 2016 еллар |
| 1.6. | Хан төрбәсе, XIV йөз | 2010 – 2016 еллар |
| 1.7. | Кече манара, XIV йөз | 2010 ел |
| 1.8. | Ак пулат, XIV йөз (хәрәбәләр) | 2010 – 2016 еллар |
| 1.9. | Көнчыгыш пулаты (хәрабәләр), XIV йөз | 2010 – 2016 еллар |
| 1.10. | Кече шәһәрчек (хәрабәләр), XIII – XIV йөзләр: Төньяк һәм Көньяк биналар, Сулык булган бина | 2010 – 2016 еллар |
| 1.11. | Кызыл пулат (хәрабәләр), XIV йөз | 2011 – 2016 еллар |
| 1.12. | Манаралы йорт («Хан сарае) (хәрабәләр), 1240 еллар | 2010 – 2016 еллар |
| 1.13. | Мавзолейлар комплексы (хәрабәләр), XIV йөз | 2011 – 2016 еллар |
| 1.14. | XVIII йөз ахыры – XIX йөз башы сәүдә лавкасы, Назаровлар ур., 67 нче йорт | 2011 – 2016 еллар |
| 1.15. | Бухтуловларның Назаровлар урамындагы 67 нче йортта урнашкан сәүдә лавкасы, XIX йөз | 2011 – 2016 еллар |
| 1.16. | XIX йөз торак йортлары, Назаровлар урамы, 67 нче йорт | 2011 – 2016 еллар |
| 1.17. | Ядкәрләр территорияләрен төзекләндерү | 2010 – 2016 еллар |
| 1.18. | Шәһәр базары, XIII – XIV йөзләр | 2012 – 2015 еллар |
| 1.19. | Гражданнарның торак йортлары биналары (хәрабәләр) XIV йөз | 2014 – 2015 еллар |
| 1.20. | Торак кирпеч йортлар, Назаровлар урамы, 5 нче йорт, 18 нче йорт, 35 нче йорт, 45 нче йорт, 67 нче йорт, Мөхәммәдьяр урамы, 7 нче йорт | 2015 – 2016 еллар |
| II бүлек. «Свияжск утрау-шәһәре» истәлекле урынының дини оешмаларга файдалануга бирелгән архитектура истәлекләрен ремонтлау, реставрацияләү, һәлакәттән саклау, консервацияләү эшләре | | |
| 2.1. | Успение монастыре ансамбле, XVI – XVII йөзләр: | |
| 2.1.1. | Успение соборы, 1560 ел, төзүче – Постник Яковлев | 2010 – 2016 еллар |
| 2.1.2. | Никола чиркәве, 1556 ел, төзүче – Постник Яковлев | 2010 – 2016 еллар |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 2.1.3. | Архимандритлар корпусы, XVIII йөз | 2010 – 2015 еллар |
| 2.1.4. | Братлар корпусы, XVI – XVIII йөзләр | 2010 – 2015 еллар |
| 2.1.5. | Монастырь училищесы, XVIII йөз | 2010 – 2015 еллар |
| 2.1.6. | Чиркәү белән ирләр монастыре киртәсе (капка өсте) | 2010 – 2016 еллар |
| 2.1.7. | Ядкәрләр территорияләрен төзекләндерү | 2010 – 1016 еллар |
| 2.1.8. | Успение монастыре ансамбле, XVI – XVII йөзләр: кар базы | 2014 – 2015 еллар |
| 2.2. | Иоанн-Предтеча монастыре ансамбле, XVI – XIX йөзләр: | |
| 2.2.1. | Троицк чиркәве, 1551 ел | 2010 – 2016 еллар |
| 2.2.2. | Сергий чиркәве, 1604 ел | 2010 – 2016 еллар |
| 2.2.3. | «Всех Скорбящих Радость» соборы, 1898 – 1906 еллар, архитекторы – Ф.Н.Малиновский | 2010 – 2015 еллар |
| 2.2.4. | Братлар корпусы (ашау-эчү өчен) | 2011 – 2015 еллар |
| 2.2.5. | Братлар корпусы (настоятельләр) | 2013 – 2015 еллар |
| 2.2.6. | Киртә | 2011 – 2015 еллар |
| 2.2.7. | Ядкәрләр территорияләрен төзекләндерү | 2010 – 2016 еллар |
| 2.3. | Константин һәм Елена чиркәве, XVII йөз | 2010 – 2015 еллар |
| III бүлек. «Свияжск утрау-шәһәре» истәлекле урынының торак һәм граждан архитектура истәлекләрен хәзерге көндә файдалану өчен ремонтлау, реставрацияләү, һәлакәттән саклау, консервацияләү һәм җайлаштыру эшләре | | |
| 3.1. | Казна корылмаларының биналар комплексы (казначылык, дәүләт урыннары, төрмәләр, төрмәнең хезмәт бүлмәләре, хастаханәләр, мунчалар) 1838-1840 еллар, XIX йөз ахыры – XX йөз башы | 2010 – 2015 еллар |
| 3.2. | Инженерлык корпусы казармалары, XIX йөз ахыры (бер катлы һәм ике катлы биналар) | 2010 – 2015 еллар |
| 3.3. | Административ бина, XIX йөз (гарипләр йорты) | 2010 – 2015 еллар |
| 3.4. | Сәүдәгәр Каменев йорты, XIX йөз ахыры | 2010 – 2011 еллар |
| 3.5. | Җәмәгатьчелек бинасы, XX йөз башы (административ бина) | 2010 – 2015 еллар |
| 3.6. | Колонналы портиклы торак йорт, XIX йөз | 2011 – 2016 еллар |
| 3.7. | Суэтем башнясы бинасы, XIX йөз ахыры | 2011 – 2015 еллар |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 3.8. | Успение-Богородица монастыреның атлар сарае биналары комплексы, XVIII йөз | 2010 – 2015 еллар |
| 3.9. | XVI – XVIII йөзләрдәге гыйбадәтханәләр: Рождествено соборы, София, Никола, Благовещение чиркәүләре хәрабәләре | 2012 – 2015 еллар |
| 3.10. | Башлангыч һөнәрчелек мәктәбе һәм янгын обозы бинасы, XIX йөзнең 70 нче еллары – XX йөз башы | 2011 – 2016 еллар |
| 3.11. | Земство хастаханәсе биналары комплексы, XIX йөзнең 70 нче еллары | 2011 – 2015 еллар |
| 3.12. | Свияжск земство управасының архив бинасы, 1870 еллар, 1907 ел | 2011 – 2015 еллар |
| 3.13. | XVIII – XIX йөзләрдәге өяз училищесы, чиркәү-мәхәллә мәктәбе бинасы, XIX йөз ахыры – XX йөз башы, Крылов йорты, 1834 ел | 2012 – 2016 еллар |
| 3.14. | Шәһәр башлыгы Ф.П.Поляков йорты, XIX йөз ахыры | 2012 – 2015 еллар |
| 3.15. | Тимофеев – Терентьев – Бровкин – Дьячковлар йорты, XIX йөз ахыры | 2012 – 2015 еллар |
| 3.16. | Сәүдә лавкасы белән Агафонов йорты, XIX йөз ахыры | 2012 – 2015 еллар |
| 3.17. | Икмәк пешерү йорты бинасы, XIX йөз ахыры | 2012 – 2015 еллар |
| 3.18. | Торак йорт, XIX йөз ахыры | 2012 – 2015 еллар |
| 3.19. | Сәүдә бинасы, XIX йөз башы | 2012 – 2015 еллар |
| 3.20. | Иоанн Предтеча хатын-кызлар монастыреның братлар корпуслары:<br>Троица урамы, 12 нче йорт адресы буенча урнашкан братлар корпусы;<br>Троица урамы, 14 нче йорт адресы буенча урнашкан братлар корпусы | 2011 – 2016 еллар |
| 3.21. | Тарихи торак йортларны реставрацияләү һәм җайлаштыру | 2013 – 2016 еллар |
| 3.22. | Ядкәрләр территорияләрен төзекләндерү | 2010 – 2016 еллар |
| 3.23. | Благовещение чиркәве (хәрабәләр) | 2012 ел |
| 3.24. | Успенская урамы, 20 нче йорт адресы буенча урнашкан бер катлы агач йорт | 2014 – 2016 еллар |
| 3.25. | Троица урамы, 4нче йорт адресы буенча урнашкан ике катлы агач йорт | 2015 – 2016 еллар |
| IV бүлек. Археологик мәдәни катламның сакланышын тәэмин итү | | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 4.1. | Болгар шәһәрлеге территориясендә археологик коткару кыр эшләре | 2010 – 2016 еллар |
| 4.2. | «Свияжск утрау-шәһәре» истәлекле урыны территориясендә археологик коткару кыр эшләре | 2010 – 2016 еллар |
| | V бүлек. Музей предметларын һәм коллекцияләрен реставрацияләү һәм консервацияләү | |
| 5.1. | «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең музей предметларын һәм коллекцияләрен реставрацияләү һәм консервацияләү:<br>кыйммәтле металлардан һәм асылташлардан эшләнгән предметлар коллекциясе;<br>нумизматика коллекциясе;<br>эпиграфика коллекциясе;<br>керамика коллекциясе;<br>пыяла коллекциясе;<br>металл коллекциясе;<br>гарәп графикасындагы язма истәлекләр, XIX – XX йөзләр;<br>сурәтләнгән чыганаклар (рәсем сәнгате коллекциясе) | 2011 – 2016 еллар |
| 5.2. | «Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе музей предметларын һәм коллекцияләрен реставрацияләү һәм консервацияләү:<br>Свияжск иконалары, XVI – XIX йөзләр;<br>Свияжск полихром сынлы сәнгате;<br>археология предметлары;<br>язма чыганаклар;<br>күннән эшләнгән предметлар;<br>керамикадан эшләнгән предметлар;<br>агачтан эшләнгән предметлар | 2011 – 2016 еллар |
| | VI бүлек. Мәдәният учреждениеләренең куркынычсызлыгын тәэмин итү | |
| 6.1. | Саклык-янгын сигнализациясе, видеокүзәтү, «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе биналарына һәм территорияләренә керүне тикшерүдә тоту һәм аның белән идарә итү системаларын үз эченә алган комплекслы (интеграцияләнгән) куркынычсызлык, элемтә һәм идарә системасын төзү | 2011 – 2016 еллар |
| 6.2. | Саклык-янгын сигнализациясе, видеокүзәтү, «Свияжск | 2011 – 2016 еллар |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе биналарына һәм территорияләренә керүне тикшерүдә тоту һәм аның белән идарә итү системаларын үз эченә алган комплекслы (интеграцияләнгән) куркынычсызлык, элемтә һәм идарә системасын төзү | |
| VII бүлек. «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе | | |
| 7.1. | Музей функциясе булган елга вокзалы (Болгар цивилизациясе музее) төзү | 2010 – 2013 еллар |
| 7.2. | Идел буе болгарлары 922 елда дәүләт дине буларак ислам кабул итүгә багышланган истәлекле билге (ядкәр) төзү | 2010 – 2013 еллар |
| 7.3. | Түбәндәге музей экспозицияләрен төзү (шул исәптән махсуслаштырылган музей җиһазларын сатып алу):<br>музей функциясе булган елга вокзалында «Болгар цивилизациясе»;<br>«Спас өязе һәм Болгар авылы тарихы»;<br>«Урта гасырлардагы Болгарда христиан дине»;<br>«Болгар шәһәрлегенең саклану корылмалары»;<br>Көнчыгыш һәм Төньяк мавзолейларда, Хан төрбәсендә һәм Кара пулатта;<br>Табиб йортында «Идел буе Болгариясенең химия, медицина һәм фармакология музее»;<br>ачык һавада «Болгар шәһәренең урта гасырлардагы һөнәрләре» интерактив экспозициясе;<br>«Язу» экспозициясе;<br>Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы | 2011 – 2016 еллар |
| 7.4. | Икмәк музеен (борынгы заманнардан алып XX йөз башына кадәр Татарстан территориясендә игенчелек һәм икмәк җитештерү тарихы музеен) төзү | 2010 – 2015 еллар |
| 7.5. | Идел буе болгарлары 922 елда дәүләт дине буларак ислам динен кабул итүгә бәйле еллык чараларны үткәрү чорында палаткалар шәһәрчеге урнаштыру | 2010 – 2015 еллар |
| 7.6. | Кече шәһәрчек районында мәдрәсә белән мәчет комплексы төзү | 2010 – 2015 еллар |
| 7.7. | Автомобильләр керү юлын төзү, тиешле юл өслеген ремонтлау һәм төзекләндерү | 2010 – 2012 еллар |
| 7.8. | Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы объектларын газ, су белән тәэмин итү һәм аларга канализа- | 2010 – 2012 еллар |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | ция-насос станциясе ясау | |
| 7.9. | Идел елгасының яр буен (Куйбышев сусаклагычы) и Болгар шәһәрлегенең өске мәйданын төзекләндерү | 2011 ел |
| 7.10. | Табиб йортын һәм һөнәрчелек остаханәләрен төзү (Идел буе Болгарының химия, медицина һәм фармакология музее, шулай ук борынгы болгарларның һөнәри процессларын торгызу) | 2011 – 2013 еллар |
| 7.11. | Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы өчен хуҗалык корылмалары төзү | 2010 – 2015 еллар |
| 7.12. | «Габдрахман сәхабә коесы» («Капитанский колодец») изге чыганак комплексы территориясен реконструкцияләү һәм төзекләндерү | 2012 – 2014 еллар |
| 7.13. | Болгар шәһәрлегенә керә торган Көнбатыш һәм Көнчыгыш капкаларын төзү | 2012 ел |
| 7.14. | Фестивальләр-вакыйгалар комплексын төзү | 2012 – 2013 еллар |
| 7.15. | Проект документларына экспертиза үткәрүгә чыгымнар | 2012 – 2016 еллар |
| 7.16. | Болгар шәһәрлеге объектларын музейлаштыру | 2015 – 2016 еллар |
| 7.17. | Болгар шәһәрлегенә керә торган төркемнәр | 2015 – 2016 еллар |
| 7.18. | Болгар шәһәрендә елга вокзалының өске мәйданын төзекләндерү районындагы археологик зона | 2015 – 2016 еллар |
| 7.19. | Мәчет һәм мәдрәсә комплексы өчен чистарту корылмалары | 2015 – 2016 еллар |
| 7.20. | Музей коллекцияләрен тулыландыру | 2016 ел |
| 7.21. | Килүчеләрне исәпкә алу системасын төзү | 2016 ел |
| 7.22. | Ядкәрләр территорияләрен төзекләндерү | 2016 ел |
| VIII бүлек. «Свияжск утрау-шәһәре» истәлекле урыны | | |
| 8.1. | «Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең музей экспозицияләрен төзү (шул исәптән махсус музей җиһазлары белән комплектлау):<br>Успение монастыреның Никола чиркәвендәге музей;<br>күргәзмә залы һәм сервис үзәге (башлангыч һөнәрчелек мәктәбе һәм янгын обозы бинасы);<br>агач музее (археологик зона) | 2011 – 2016 еллар |
| 8.2. | Туристлар кабул итү өчен автостанция белән берләштерелгән елга вокзалы комплексы төзү | 2010 – 2011 еллар |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 8.3. | Иоанн-Предтеча монастыре территориясендә монастырь ихтыяҗлары өчен хуҗалык блогы төзү | 2010 – 2013 еллар |
| 8.4. | Электр белән тәэмин итү челтәрләре төзү | 2010 ел |
| 8.5. | Урта һәм түбән басымлы газүткәргечләр төзү | 2010 ел |
| 8.6. | Автомобиль юлларын төзү һәм төзекләндерү, автотранспорт өчен туктап тору мәйданчыклары | 2010 – 2011 еллар |
| 8.7. | Мәйданнарны һәм яр буйларын төзекләндерү | 2010 – 2015 еллар |
| 8.8. | «Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе өчен хуҗалык-көнкүреш блогын төзү | 2011 – 2015 еллар |
| 8.9. | Проект документларына экспертиза үткәрүгә чыгымнар | 2012 – 2016 еллар |
| 8.10. | «Свияжск утрау-шәһәре» истәлекле урыны территориясендәге археологик зонаның саклану корылмасын төзү | 2014 – 2016 еллар |
| 8.11. | Свияжск утравына керә торган төркем | 2014 – 2016 еллар |
| 8.12. | Успение монастыренең казаннар бинасы, XVI – XVII йөзләр | 2015 ел |
| 8.13. | Музей коллекцияләрен тулыландыру | 2016 ел |
| 8.14. | Килүчеләрне исәпкә алу системасын төзү | 2016 ел |

---